СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.10.2024 г. Заинск № 353

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2024 елның 30 июлендәге 342 номерлы карары белән расланган Зәй муниципаль районы чикләрендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы федераль законнарга, Зәй муниципаль районы Уставына таянып , Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2024 елның 30 июлендәге 342 номерлы карары белән расланган Зәй муниципаль районы чикләрендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 14.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"14.3 планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 1 өлешендәге 3-6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә тикшерү уздырылган очраклар керми.»;

1.2. 15.3 пунктта «1 өлешенең 3 - 6 пунктларында» сүзләреннән соң «,3 өлешендә» сүзләрен өстәргә.;

1.3. 15.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15.8. Рейд тикшерүе прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-6 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә үткәрелгән очраклар керми.».

2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Советының Экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, ТКХ һәм транспорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**